# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасында торак
фондын хосусыйлаштыру турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендәге дәүләт һәм җирле торак фондын хосусыйлаштыруның үзенчәлекләрен билгели, торакка милек мөнәсәбәтләрен үзгәртүнең хокукый, җәмгыяви һәм икътисадый нигезләрен урнаштыра.

Гражданнарның торакка ихтыяҗларын канәгатьләндерү ысулларын ирекле сайлау хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук торак фондыннан файдалануны һәм аны карап торуны яхшырту - Законның төп максаты.

## I БҮЛЕК. ТӨП НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1 статья. Торакны хосусыйлаштыру - гражданнарның дәүләт һәм җирле торак фонды йортларындагы үзе биләүче торак урыннарын, торакның гомуми мәйданына һәм кулланылыш сыйфатына карамастан, ирекле рәвештә үз милкенә бушлай күчерүләре ул.

2 статья. Дәүләт торак фонды тулы хуҗалык итү хокукы рәвешендә беркетелгән торак фондына ия булган дәүләт предприятиеләренең, үз идарәчелегенә торак фонды тапшырылган дәүләт учреждениеләренең һәм оешмаларының торак фондыннан гыйбарәт.

Җирле торак фонды тулы хуҗалык итү хокукы рәвешендә беркетелгән торак фондына ия булган халык депутатларының җирле Советларының, җирле предприятиеләрнең үз идарәчелегенә торак фонды

тапшырылган җирле учреждениеләрнең һәм оешмаларның торак фондыннан гыйбарәт.

3 статья. Дәүләт һәм җирле торак фонды йортларындагы яллау килешүе буенча торак урыннарын биләүче гражданнар әлеге торак урыннарын шушы Законда каралган шартларда гаиләнең /гаиләләрнең/ бергә яшәүче барлык балигъ булган әгъзаларының язма ризалыгы нигезендә уртак милке итә ала.

4 статья.

Торак милекчесенә әверелгән гражданнар бу торак урыннарын үзләре теләгәнчә биләләр, файдаланалар һәм аларга хуҗа булалар: сата, васыять итә, арендага бирә һәм гамәлдәге законнарга каршы килмәүче башка гамәлләр кыла алалар.

Дәүләт һәм җирле торак фонды йортларындагы торак урыннарын хосусыйлаштырган милекчеләр инженер җиһазларыннан һәм уртак куллану урыннарыннан файдаланалар, ә ширкәтләргә яисә башка берләшмәләргә берләшкәннәр бу йортта биләүче мәйданга тәңгәл рәвештә инженер җиһазларының һәм уртак куллану урыннарының хуҗалары булалар.

Торак урынына милекчелек хокукын тормышка ашыру йортның инженер җиһазларыннан һәм уртак кулланылыш урыннарыннан файдалану яисә аларны биләү башка затларның хокукларын бозмаска һәм гамәлдәге законнар нигезендә яклanучы мәнфәгатьләренә кагылмаска тиеш.

5 статья. Авария хәлендәге, тулай торакларлардагы, махсуслаштырылган йортлардагы һәм ябык хәрби шәһәрчекләрнең йортларындагы торак урыннары хосусыйлаштырылмый.

Халык депутатларының җирле Советлары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән берлектә, кәсби берлекләрнең - профсоюзларның /аларның тиешле органнары сыйфатында/ фикерен исәпкә алып, алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Рес-

Республикасы законнары нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләтләр тапшырылган вәкилләре хезмәт итү өчен кирәкле хосусыйлаштырылмаучы торак урыннарының өлешен билгели.

6 статья. Хосусыйлаштырылган торак йортлар һәм алар янындагы территорияләр урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалану һәм аларны биләү Татарстан Республикасы законнарында күрсәтелгән тәртиптә һәм шартларда гамәлгә ашырыла.

7 статья. Нинди ведомствога карауларына бәйсез рәвештә, торак урыннарын гражданнар милкенә күчерү торактан файдалануның тиешле оешмалары аша, гражданнарның гаризалары нигезендә халык депутатларының җирле Советлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8 статья. Торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру халык депутатларының җирле Советлары исеменнән торактан файдалану оешмасы белән милкенә торак фонды алучы граждан арасында төзелгән тиешле шартнамә нигезендә беркетелә.

Шартнамә гариза тапшырылган көннән бер айдан да соңга калмыйча хәл ителергә тиеш.

Хосусыйлаштырылган торак урынына милекчелек хокукы җирле администрация яисә ул вәкаләт биргән орган тарафыннан теркәлгән шартнамә төзелгән мизгелдән үз көченә керә.

Әлеге шартнамәләрнең нотариаль раслануы таләп ителми. Гражданнардан дәүләт пошлинасы алынмый.

9 статья. Торак шартларын рәтләүгә мохтаҗ гражданнар өчен торак урынын исәпкә алу һәм аларга торак урынын бирү тәртибе гамәлдәге законнар нигезендә саклана һәм билгеләнә.

Дәүләт һәм җирле торак фонды йортларындагы торак урыннарын яллау шартларында биргәндә алдан билгеләнгән ташламалар саклана.

Торак шартларын рәтләүгә мохтаҗ Бөек Ватан сугышы гариплəре һәм билгеләнгән тәртиптә аларга тиңләштерелгән затлар, хезмәттән гарипләр, шулай ук балачактан гарипләр, сугыш ветераннары, дәүләт кушкан вазыйфаларны үтәгәндә һәлак булганнарның гаиләләре, рәсми рәвештә билгеләнгән яшәү минимумыннан да кимрәк керемле гаиләләр, өч һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләр өчен дәүләт һәм җирле торак фонды йортларындагы торак урынын торак яллау шартларында биргәндә ташламалар гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

Әлеге статьяның өченче өлешендә күрсәтелгән ташламаларны алу хокукы Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка төр гражданнарга да бирелергә мөмкин.

10 статья. Халык депутатлары җирле Советының карары нигезендә дәүләт һәм җирле торак фондын хосусыйлаштыру буенча комиссия төзелә. Комиссия составына халык депутатларын, кәсби берлекләрнең вәкилләрен, ә алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләт тапшырылган вәкилләрен, кирәк чакта - хәрби частьләрнең вәкилләрен кертү мәҗбүри.

Комиссия дәүләт һәм җирле торак фондын хосусыйлаштыру комиссиясе хакында Татарстан Республикасының Дәүләт милкәтенә идарә буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган нигезләмәгә таянып эш итә.

11 статья. Торак урынын хосусыйлаштырудан баш тарткан очракта гражданның әлеге торак урынында яллау шартнамәсе нигезендә яшәү хокукы гамәлдәге законнар тарафыннан саклана.

12 статья. "Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә

232

ашыруны Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, халык депутатларының җирле Советлары тикшереп тора.

## 2 БҮЛЕК. ТОРАКНЫ ХОСУСЫЙЛАШТЫРУНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ

13 статья. Һәр граждан дәүләт һәм җирле торак фонды йортларындагы үзе биләүче торак урынын бер генә мәртәбә хосусыйлаштыра ала.

14 статья. Хосусыйлаштырылмый торган торак урынында яисә торак белән тәэмин ителешнең республикада ирешелгән уртача дәрәҗәсеннән түбәнрәк торак шартларына ия булган /һәр кешегә 16,2 кв.м. гомуми мәйдан/ Татарстан Республикасының һәр гражданы хосусыйлаштыруның өстәмә түләү чаралары рәвешендә компенсация алырга хаклы.

Гражданнар өчен түбәндәге күләмнәрдә компенсацияләр билгеләнә:

| | |
|---|---|
| торыр урыны булмаган, тулай торакларда, махсуслаштырылган йортларда, авария һәм хәрабә хәлендә дип табылган торак урыннарында яшәүче гражданнарга | - 40 мең сум исемле хосусыйлаштыру хисаплары /кертемнәре/; |
| ябык хәрби шәһәрчекләрдә, хезмәт торак урыннарында яшәүче гражданнарга | - 30 мең сум исемле хосусыйлаштыру хисаплары /кертемнәре/; |
| һәр кешегә гомуми мәйданы 5 кв.метрдан артмаган торак белән тәэмин ителгән гражданнарга | - 30 мең сум исемле хосусыйлаштыру хисаплары /кертемнәре/; |
| һәр кешегә гомуми мәйданы 5 кв.метрдан 10 кв.метрга кадәр булган торак белән тәэмин ителгән гражданнарга | - 20 мең сум исемле хосусыйлаштыру хисаплары /кертемнәре/; |
| һәр кешегә гомуми мәйданы 10 кв.метрдан 16,2 кв.метрга кадәр булган торак белән тәэмин ителгән гражданнарга | - 10 мең сум исемле хосусыйлаштыру хисаплары /кертемнәре/; |

һәр кешегә гомуми мәйданы 10 кв.метрдан 16,2 кв.метрга кадәр булган торак белән тәэмин ителгән гражданнарга - 10 мең сум исемле хосусыйлаштыру хисаплары /кертемнәре/.

Югарыда күрсәтелгән категорияләрнең бер үк вакытта икесенә һәм аннан да күбрәгенә кертелүче граждан иң зур компенсацияне алырга хаклы.

Торак-төзелеш кооператив йортларында яшәүче Татарстан Республикасының һәр гражданы өстәмә хосусыйлаштыру түләүләре рәвешендә бирелүче 10 мең сумлык исемле хосусыйлаштыру хисапларын /кертемнәрен/ компенсация сыйфатында алырга хаклы.

Граждан, биләгән торак урынының милек рәвешенә карамастан, компенсацияне бер мәртәбә генә алырга хаклы.

15 статья. Гражданнарга компенсация рәвешендә бирелә торган исемле хосусыйлаштыру хисапларын /кертемнәрен/ ачу һәм куллану тәртибе "Татарстан Республикасында исемле хосусыйлаштыру хисаплары /кертемнәре/ турында" Татарстан Республикасы Законы тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт һәм җирле мөлкәтне сатып алу өчен исемле хосусыйлаштыру хисапларын /кертемнәрен/ куллану 1993 елның 1 гыйнварена беркетелгән бәяләрдә башкарыла.

16 статья. Халык депутатларының җирле Советлары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, гражданнарның ризалыгы белән, аларның мөлкәтләрендә булган торакны, киләчәктә нәтиҗәлерәк булу максатыннан чыгып, сатып алырга хаклы.

17 статья. Дәүләт яисә җирле предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның милек рәвешләре үзгәргәндә, бу пред-

приятиеләргә тулы хуҗалык итү рәвешендә беркетелгән яки оешмаларга һәм учреждениеләргә үз идарәчелегенә тапшырылган торак фонды гражданнарның торакка булган барлык хокукларын саклаган килеш, шул исәптән торакны хосусыйлаштыруга хокукларын да кертеп, әлеге предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның, башка хокукый затларның хокукларын дәвам итүчеләрнең тулы хуҗалык итүенә яисә үз идарәчелегенә яки халык депутатларының җирле Советларына бирелә.

18 статья. Торакны хосусыйлаштыру мәсьәләләре хәл ителгәндә гражданның хокуклары бозылса, ул халык депутатларының җирле Советы карары нигезендә төзелгән дәүләт һәм җирле торак фондын хосусыйлаштыру комиссиясенә мөрәҗәгать итә ала.

Торакны хосусыйлаштыру турындагы мәсьәлә бер ай эчендә каралмаган, торакны хосусыйлаштырудан баш тарткан очракта, торакны хосусыйлаштыру мәсьәләләрен хәл иткәндә гражданның хокуклары бозылган башка очракларда ул судка мөрәҗәгать итә ала.

## 3 БҮЛЕК. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ХОСУСЫЙЛАШТЫРЫЛГАН ТОРАКНЫ ФАЙДАЛАНУ һӘМ АҢА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ БУЕНЧА ТӨП ТӨШЕНЧӘЛӘР

19 статья. Хосусыйлаштырылган торак урыннарына хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау вазыйфалары дәүләтнең хосусыйлаштыруга кадәр хезмәт күрсәткән торак-куллану һәм ремонт-төзелеш оешмалары өстендә кала.

Торак урыннарының милекчеләре, милек рәвешләренә карамастан, башка предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның да хезмәт күрсәтүләреннән файдалана алалар.

20 статья. Хосусыйлаштырылган торак урыннарын һәм бөтен йортны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, коммуналь хезмәт күрсәтү /җылыту, электр, газ, су һәм канализация белән тәэмин итү/ белән бәйле чыгымнарны дәүләт һәм җирле торак фондына хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән ставкалар нигезендә аларның милекчеләре түли.

Җирле хезмәт күрсәтүләр, торак урыннарны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү белән бәйле чыгымнарны түләү буенча элек билгеләнгән ташламалар саклана.

Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышы гариплэре, билгеләнгән тәртиптә аларга тиңләштерелгән затлар, хезмәттән гариплэр, балачактан гариплэр, картлык буенча пенсионерлар, дәүләт кушкан вазыйфаларны үтәгәндә һәлак булганнарның гаиләләре, өч һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләр яшәүче йортларны һәм андагы торак урыннарын, милек рәвешләренә карамастан, ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү белән бәйле чыгымнарны түләү буенча ташламалар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Әлеге статьяның өченче өлешендә күрсәтелгән ташламаларга хокук Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка төр гражданнарга да бирелергә мөмкин.

21 статья. Хосусыйлаштырылган торак урыннарын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, дәүләт һәм җирле торак фонды йортлары өчен билгеләнгән торак фондын ремонтлауның һәм аңардан файдалануның бердәм кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәгән килеш, милекчеләрнең үз исәпләреннән башкарыла.

Шул максатларда милекчеләр ширкәтләр һәм башка берләшмәләр оештыра алалар.

22 статья. Торак урыннарының милекчеләре, хезмәт күрсәтү белән, инженерлык җиһазларын, йорттагы уртак куллану урыннарын ремонтлау һәм өй алды территориясен карап тору белән бәйле чыгымнарны үзе биләгән торак мәйданы күләменә чагыштырма рәвештә түләүдә катнаша.

23 статья. Хосусыйлаштырылган торак фондының техник халәтен һәм үз вакытында ремонтлануын, өй алды территорияләрен төзекләндерүне халык депутатларының җирле Советлары тикшереп тора.

24 статья. Хосусыйлаштырылган торак урыннарыннан, инженерлык җиһазларыннан, коммуникацияләрдән һәм өй алды территориясеннән файдалану кагыйдәләрен бозу законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка китерә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның I5 июле
№ I936-XII